Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына үзгәреш кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 5 өлешенә (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2025, № 85 (I өлеш); 2026, № 17 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5. Дәүләт хезмәткәрләре федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә мәҗбүри дәүләт дактилоскопия теркәлүен һәм мәҗбүри дәүләт геном теркәлүен узарга тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 7 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 8 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законны (алга таба – 2026 елның 8 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон) үтәү максатыннан эшләнде.

2026 елның 8 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законга федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә дәүләт граждан хезмәткәрләренең дәүләт геном теркәлүе турында нигезләмәләрен төгәлләштерүгә юнәлтелгән өлешендә үзгәрешләр кертелгән.

Моңа бәйле рәвештә закон проектында «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына охшаш үзгәрешләрне кертү каралган.

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында»
Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына үзгәреш кертү хакында»
Татарстан Республикасы законын итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан
дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул
ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары
һәм башка норматив хокукый актлары
ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын итү Татарстан Республикасы законнарын һәм норматив хокукый актларын үз көчен югалткан дип тануны, туктатып торуны, аларга үзгәрешләр кертүне яисә аларны кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына үзгәреш кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанслау таләп итми.